КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 июнь г.Казань № 405

2024 елда «Яңа музыка» яшьләр симфоник оркестрын булдыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән субсидия рәвешендә грант бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда «Яңа музыка» яшьләр симфоник оркестрын булдыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән субсидия рәвешендә грант бирү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2004 ел, 5 июнь, 405 нче
карары белән расланды

2024 елда «Яңа музыка» яшьләр симфоник оркестрын булдыру
һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән
субсидия рәвешендә грант бирү тәртибе турында
нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә 2024 елда «Яңа музыка» яшьләр симфоник оркестрын булдыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен «И.В.Әухәдиев исемендәге Казан музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә (алга таба – учреждение) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән субсидия рәвешендә грант (алга таба – грант) бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Грант бирүнең максаты – музыкантларның махсуслаштырылган компетенцияләрен үстерү һәм студентлар коллективы оркестрын профессиональ дәрәҗәдә үзгәртеп оештыру өчен шартлар тудыру буенча «Яңа музыка» яшьләр симфоник оркестрын булдыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү.

Грант турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

3. Грант Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен грант бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән, бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен гамәлгә ашырган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык).

4. Грант 11 871,1 мең сум күләмендә бирелә.

5. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнар юнәлешләре:

а) «Яңа музыка» яшьләр симфоник оркестры эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итүче учреждение хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү (Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләрне исәпкә алып);

б) җәлеп ителгән белгечләрнең хезмәте өчен түләү (Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт өчен түләүләүргә исәпләүләрне исәпкә алып);

в) концерт костюмнары, аяк киемнәре сатып алу;

д) сәхнә җиһазлары һәм музыка уен кораллары сатып алу.

Учреждениегә, шулай ук учреждение белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия

Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.

6. Грант бирү нәтиҗәсе – грант бирү елыннан соң килә торган елның 25 декабренә кадәр учреждение тарафыннан иҗади проектлар гамәлгә ашыру, шул исәптән:

а) милли мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә гамәлгә ашырылган иҗади проектлар саны – кимендә бер;

е) дөньякүләм симфоник музыканың төп юнәлешләрен үзләштерүгә, балалар һәм яшьләр арасында симфоник оркестр эшчәнлеген популярлаштыруга юнәлдерелгән, гамәлгә ашырылган иҗади проектлар саны – кимендә бер.

7. Министрлык һәм учреждение арасында грант бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1нче көненә Учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

а) чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

б) учреждение экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

в) учреждение БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

г) учреждение әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

д) учреждение «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

е) учреждениенең бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3

пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

ж) учреждениенең башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

з) учреждение үзгәртеп оештыру (башка юридик затны учреждениегә кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, учреждение эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмау;

и) дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки учреждениенең баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

8. Килешү төзү өчен учреждение Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 енче көненә урнашу урыны буенча салым органында учреждение исәпкә куелу урыны буенча салым органы тарафыннан бирелгән учреждениенең салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү йөкләмәләрен үтәве турында белешмә кәгазе (мондый документ учреждение тарафыннан тапшырылмаган очракта, Министрлык аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

б) гариза биргән датага Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (учреждение мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

в) дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм (яки) Федераль салым хезмәте тарафыннан расланган форма буенча килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1нче көненә җитәкчегә, коллегиаль башкарма орган әгъзаларына, бер кеше башкара торган башкарма орган функцияләрен башкаручы затларга яисә учреждениенең баш бухгалтерына (баш бухгалтеры булганда) карата соратып алына торган мәгълүмат булмау турында белешмә кәгазе (учреждение мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

г) учреждение җитәкчесе тарафыннан имзаланган, учреждениенең килешү төзергә планлаштырыла торган айның 1нче көненә әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә учреждениегә карата куела торган таләпләргә туры килүе турында (гарантия хаты (ирекле формада).

9. Учреждение тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән алып 20 эш көне эчендә Министрлык документларны тикшерә һәм грант бирү турында яисә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә. Грант бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә әлеге документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

б) учреждение биргән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

10. Грант бирү Министрлык һәм аңа карата грант бирү турында карар кабул ителгән учреждение арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә грант бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

11. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант бирү максатлары;

грант күләме;

грантны күчерү сроклары һәм тәртибе;

грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

«грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

грантны кире кайтару очраклары һәм тәртибе;

грантны мәҗбүри түләтү буенча чаралар кабул итү сроклары;

грант бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык;

учреждениенең, учреждение белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шарты һәм тәртибе;

әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән максат өчен килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешелмәгәндә килешүне өзү турында шарт;

учреждениегә, шулай ук учреждение белән төзелгән шартнамәләр нигезендә

акча алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операциялардән тыш) сатып алу тыела;

грант күчерү өчен план-график.

Учреждение кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Учреждениене бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук учреждение бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, учреждение тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган йөкләмәләр һәм грантның файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

Министрлыкның килешүнең яңа шартларын килештерү турында карары кабул ителгән очракта, аңа Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә өстәмә килешү төзелә.

12. Грантны күчерү килешүдә каралган грантны күчерүнең план-графигы нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган учреждениенең шәхси счетларына гамәлгә ашырыла.

13. Учреждение хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 енә кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча Министрлыкка финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап кертә.

14. Министрлык әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән хисапларны әлеге хисаплар бирелгән көннән алып 20 эш көненнән артмаган срокта тикшерә.

Кирәк булганда Министрлык килешүдә учреждение тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгели.

15. Министрлык учреждениенең грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән әлеге Нигезләмәдә һәм килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешүне һәм грант бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглау тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

16. Учреждение тарафыннан грант биргәндә билгеләнгән шартлар һәм тәртип бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр факты буенча ачыкланган бозулар булганда, шулай ук грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, учреждение

Министрлыкның язма таләбен алган көннән 30 календарь көн эчендә алынган грантны Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтара.

17. Әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемено ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, Министрлык учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына алган акчаны кире кайтарудан баш тарту турындагы хәбәрен алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә яки Министрлыкның язма таләбендә күрсәтелгән учреждение тарафыннан алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә кире кайтару срогы чыкканнан соң Россия Федерациясе законнары нигезендә аларны мәҗбүри тәртиптә кире кайтару буенча чара күрә.

18. Грантларны нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

---